МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 1/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«09» 01 2019

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2016 елның 01 ноябрендәге 189/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2016 елның 01 ноябрендәге 189/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 7 ноябрендәге 195/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Иҗтимагый совет карары нигезендә, Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый советта каралучы мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләрне һәм бәяләмәләрне бирү өчен башкарма органнарның, коммерциясез оешмаларның, фәнни учреждениеләрнең вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылырга мөмкин.

Иҗтимагый совет әгъзалары булып тормаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет чакыруы буенча Иҗтимагый совет утырышларында катнашырга мөмкин.».

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы мөдире Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА